Татарстан яшьләре

№12

(8890)

ПӘНҖЕШӘМБЕ

27 гыйнвар, 1994 ел

Бәясе килешү буенча.

* ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ * 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА *

Тагын бер күпер салынды...

Телләребез, диннәребез бик якын булса да, кайчандыр Төркия безгә ай-һай ерак иде. Заманалар үзгәрә. Кем уйлаган, Казаныбызда төрек мәдәниятенә дә урын табылыр дип. Татар белән төрек халкы арасында күперләр барлыкка килде. Шушы көннәрдә Казанның Ибраһимов проспектында төрек мәдәнияте үзәге ачылды. Аны ачуда "Төрк дөньясы араштырмалары" вакыфы башканы, Истанбул университеты профессоры Туран Язган, Татарстан Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары Зилә Вәлиева, Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев катнашты.

Тантанада Ленин районы хакимияте башлыгы Әнвәр Мөхәммәтзакиров мәдәни мәркәз ачылуны рәсмиләштергән документны бирде. Киләчәктә бу мәркәз өчен яңа бина салыначагын хәбәр итте.



Бүләкләр дә күп иде. Әнвәр әфәнде суыткыч тапшырса, Чаллыдагы бертуган Кашаповлар бирегә дә буш кул белән килмәгәннәр: телевизор һәм манаралы сәгать бүләк иттеләр.

Тантана җыр-бию белән аралашып барды.

Евгений КАНАЕВ фотолары.




Испания Шәймиевне олылый

ТР Президентының Матбугат үзәге Мадридтан хәбәр итә

24 гыйнварда Минтимер Шәймиев җитәкчелегендә Татарстан Республикасы делегациясе Испания Корольлегенә барып җитте. Мадрид аэропортында аларны Русия илчесе И.Иванов, Испаниянең икътисад министры Эдуард Диас Рамон, сәүдә буенча генераль директор Энрике Зарагоса каршылады. Шул ук көнне Мэриядә Татарстан Президенты хөрмәтенә рәсми кабул итү булды. Мэр Хосе Мария Альварос дель Мансано Мадридның 3,8 миллионлы халкы исеменнән М.Шәймиевне кайнар котлады. Аерым алганда, ул Татарстан һәм аның башкаласы, эш сөючән татар халкы һәм республиканың Русия тарихында зур урын тотуы турында яхшы белүен билгеләп үтте. "Без илләрнең эволюцион үсешен хөрмәт итеп, сезгә дуслык кулы сузабыз", - диде Альварос дель Мансано әфәнде.

Минтимер Шәймиев исә Татарстанның үзара файдалы хезмәттәшлеккә әзер булуын әйтте. Аннан соң ул испанлыларга Татарстан турында сөйләде.

Кичен Татарстан делегациясе мәдәни-сәүдә үзәге Паркесурда булды. Ул дөньяда иң зурлардан санала.



Ульян шәһәре мэры Сергей Ермаков эт һәм песи тотучылар өчен кагыйдәләр керткән. Бу кагыйдәләр буенча, фатирда бары тик бер эт һәм бер песи генә тоту рөхсәт ителә. Эт йөртергә алып чыгу вакыты 7 дән 23 сәгатькә кадәр. Алып чыкканда этнең муенында номер сугылган муенчак һәм кыска бау булырга тиеш. Исерекләр һәм 14 яшькә җитмәгән балаларга этне йөртергә алып чыгу тыела.

Казан мэрына да шушындый кагыйдәләр кертү вакыты җитмәдеме икән?

Чәйнәгеч - резинаны өреп кабарту беренче карашка гына кызык булып күренә. Әмма ул тормыш өчен куркыныч булырга да мөмкин. Рязань шәһәрендә булган фаҗига моны раслый. Өреп кабарткан резина шартлап бер кечкенә малайның тын юлын каплый һәм малай ашыгыч ярдәм килеп җиткәнче анасы күз алдында сулышы буылып үлә.

Ульян шәһәренең Ленин мемориалы шушы көннәрдә яңа "кунаклар" кабул иткән. Романовлар династиясенең 40 натурасының балавыз сыннарын аларның кан дошманы булган Ленинга багышланган экспозиция белән янәшә урнаштырганнар. Ленинга керү бушлай, ә Романовларны карарга керү өчен мең сум түләргә кирәк.



Автобуслар артык булмый

Моңарчы чит илләрдән валютага автобуслар сатып алган Татарстан якын киләчәктә аларны үзе читкә чыгара башлаячак. "КамАЗ" акционерлык җәмгыяте "Татавтотранс" ассоциациясе белән берлектә быелның апреленә үк 10 автобус эшләп чыгарачак. "КамАЗ" базасында ел азагына кадәр тагын 100 автобус конвейердан төшәр дип көтелә. Ә бер елдан автобусларны күпләп җитештерүгә керешәчәкләр.

Кан тартуы

Казанга Русиянең иң яшь гипнозчысы Антон Кафетулов килде. Фамилиясеннән үк күренгәнчә, бүген Ерак Көнчыгышта яшәгән дәвалаучының нәсел-нәсәбе Татарстанга килеп тоташа. Якын һәм ерак чит илләрдә күп йөрергә өлгергән, радио һәм телевидениенең игътибарын казанган гипнозчыны Татарстан республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы чакырып китергән.

Башың яшь - өйдә утыр!

"Яшьлек каласы" дип йөртелгән Чаллыда кичләрен бала-чага һәм яшүсмерләр күрмәсә, гаҗәпләнмәгез. Кичен алар өйләрендә утырырга тиеш - Чаллы мэры Р.Алтынбаевның фәрманы шундый. Аннан аңлашылганча, 12 яшькә кадәрле балаларга кичке җидедән соң өлкәннәрдән башка йөрү тыела. 13-16 яшьлекләрнең - кичке сигезгә, ә 17-18 яшьлекләрнең кичке тугызга кадәр җәмәгать урыннарында булырга хакы бар.

Начар хәбәр

25 гыйнвардан Казанда шәһәр транспортында йөрү бәяләре өч мәртәбәгә арттырылды. Хәзер трамвайда, троллейбуста һәм автобуста билет бәяләре 30 сум. Моны биш көн элек кенә бензин хакының чираттагы үсү нәтиҗәсе дип карарга кирәк. Татарстанда хәзер АИ-76ның литры - 210, АИ-93неке - 250, ә дизель ягулыгыныкы исә 200 сум тора.

Шул да мәгълүм булсын, шәһәр тирәсенә йөрүче поездларда билет бәясе 4 тапкыр артты. Мисал өчен, Казаннан Юдинога бару - 80, Бисктауга - 120, Зеленодолга - 160, Арчага - 280, Шәмәрдәнгә 440 сумга төшә.

Фәрит Мөхәммәтшин Согуд Гарәбстанында

26 гыйнварда Татарстан Югары Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин Согуд Гарәбстанына китте. Бу илнең короле Фахд Бен Абдель-Азиз чакыруы буенча оештырылган делегация составында башка кайбер республикаларның җитәкчеләре һәм Русиянең мөселман дине әһелләре дә бар.

Сәяхәт барышында аларны зур сәяси һәм иҗтимагый эшлеклеләр, эшмәкәрләр белән очрашулар көтә. Король һәм хакимлек итүче даирәнең гаиләләре белән танышулар да булачак. Әлеге делегацияне Русия Федераль Җыенының Федерация Советы Рәисе Рамазан Абдулатыйпов җитәкли. Татарстан делегациясендә Казан шәһәр хакимияте башлыгы К.Исхаков һәм "Татнефть" берләшмәсе генераль директоры Р.Галиев та бар.

Чиновниклар кимиячәк

Премьер-министр Мөхәммәт Сабиров журналистлар өчен матбугат конференциясе үткәрде. Башта ул Татарстан һәм Русия әзерли торган килешү турында берничә сүз әйтеп китте, аннан сорауларга җавап бирде.

М.Сабиров Татарстанда мартта үтәргә тиешле Дума һәм Федерация Советы сайлауларында үз кандидатурасын куймаячагын әйтте. Аның фикеренчә, Русиянең финанс министры Федоровның отставкага китүе файдага гына булачак. Дөрес, беренче вакытта инфляция кискен үсәчәк, ләкин Мөхәммәт Галләмович фикеренчә, аның темплары бүген дә зур, әмма бу яшерелә. Нәтиҗәдә икътисадка зур зыян салынуы мөмкин.

Премьер-министр быел Татарстанда нефть чыгару кимиячәген әйтте. "Роснефть" акционерлык җәмгыяте Татарстанның нефть чыгару өлкәсендәге эшчәнлеген кысмакчы икән. Премьер моны чишелмәслек мәсьәлә дип санамый, чөнки "Татнефть" башка оешмалар белән дә хезмәттәшлекне җайга салырга сәләтле.

М.Сабиров республика икътисадын структур рәвештә үзгәртеп кору концепциясе эшләнеләп бетүен хәбәр итте. Анда аппаратны кыскарту да каралган.

Ә иң кызыгы шул: Премьер-министрның Русия биргән ваучерлы да, Татарстан чегы да әлегә кадәр эшкә җигелмәгән һәм сейфында саклана.

30 гыйнварда 10 сәгатьтә Казанның Г.Тукай урамында Солтан мәчетен ачу тантанасы була. Дөрес, ул яңа мәчет түгел, 1867 елда ук төзелгән. Соңгы елларда аңа 36 нчы профтехучилище хуҗа иде. Ел башында мәчет мөселманнарга кайтарып бирелде. Аның имам-хатыйбы итеп хаҗи Камил Бикчәнтәй билгеләнде.

Эшкә өндәү

Яхшы хезмәт хакы алып эшләү - ярты бәхет.

Яхшы кешеләр арасында эшләү - тулы бәхет.

Ә инде хезмәт хакы да, кешеләре дә яхшы булган газета редакциясендә эшләү - икеләтә бәхет.


"Татарстан яшьләре"нә түбәндәге хезмәткәрләр кирәк:

1. Яшь журналистлар (егетләр).
2. Компьютер операторы (рәсем ясауга сәләте булган егет кеше).
3. Секретарь-машинистка.

Сайлап алу - конкурс буенча.

Мөрәҗәгать итү өчен телефоннар:

53-07-54. 53-07-52.



Татарстан Дәүләт автоинспекциясе хәбәр итүенчә, узган елны республикабыз юлларында 1023 юл вакыйгасы теркәлгән. 163 кеше һәлак булган, 1008 кеше төрле тән җәрәхәте алган. 38 авария руль артына исерек утыруга бәйле. Иң кызганычы - авария вакытында 159 бала зыян күргән. Шуларның сигезенең вакытсыз өзелгән гомерен кире кайтарып булмый.

Е.КАНАЕВ фоторепродукциясе

Миргазиян ЮНЫС

АЛЛАКЧЫЛЫККА ТАБЫНУЧЫЛАР



Беренче дәлил. Матросов турындагы миф чыкканда немецлар совет гаскәрләрен Мәскәү юнәлешендә куып киләләр иде. Фашистлар һөҗүм итә, без оборона тотабыз. Менә шул шартларда Матросов "батырлыгын" совет солдаты түгел, немец солдаты майтарырга тиеш иде. Ул килеп капларга тиеш иде күкрәге белән пулемет утын. Немецларнең һөҗүмен туктатыр өчен дот, дзотлардан без ата идек. Атакага немецлар килә иде. Мифны чыгаручылар бу турыда уйлап тормаганнар.

Икенче дәлил. Амбразура тишегеннән аткан пулеметка якын килеп булмый. Күп дигәндә - утыз, егерме, ә инде күкрәгең корыч бронядан эшләнгән очракта ун метрга якынлашып булә. Ун метр калганда пулемет уты синең күкрәгеңнән иләк ясый. Ә мәрхүм Матросов пулемет көпшәсенә килеп җиткән кенә калмаган, амбразураны күкрәге белән дә каплаган.

Өченче дәлил. Совет армиясенең пехота уставыннан, кыр тактикасыннан тыш, минем америкаләр уставын, аларның пехота гаскәрләре өчен язылган тактикаларын укыганым бар. Сугыш барганда командирларны алдан кисәтеп куялар: пулемет яки шуның ише башка корал атып торганда һөҗүм итмәскә, андый адым ясаудан солдатларны да тыярга. Устав шулай куша.

Ватан сугышында безнең җиңеп чыгуыбызның нәтиҗәсен тикшерә башлаган елларда бер немец солдатын үтерү өчен биш совет (гадәттә "урыс" солдаты) киләр, әйтерсең, сугышта башка милләтләр катнашмаган) солдатын корбан итәргә туры килгән. Хәзер инде җиде-сигез корбан биргәнбез дип аңлата башладылар. Аңлыйсызмы, Александр Матросов "батырлыгы"ның күпме совет солдатының башына җитүен? Мәрхүм Әпсәләмовны да кызганмыйча булмый. Аның

1

Минем дә язмам Вил Мирзаянов турында.

Аның турында сөйли башлаганчы Александр Матросовка тукталып китик. Герой иттек без аны, герой гына түгел, пот (икона) иттек. Күп еллар табындык. Урамнарга, мәктәпләргә аның исемен бирдек. Газиз балаларыбызны Александр Матросовтан үрнәк алырга хәтта мәҗбүр иттек һәм, аянычка каршы, бу өлкәдә зур уңышларга ирештек.

Соңгы елларда Александр Матросовның Шакирҗанов фамилияле татар булганлыгы, армиягә кадәр шактый күп хулиганлыклар кылганы турында күп яздылар. Яңадан кузгатмыйк бу мәсьәләне. Мәрхүм турында я гел әйбәт сүзләр сөйләргә, әйбәт сүз әйтерлек булмаган очракта, берни сөйләмәскә кирәк. Без Матросовның үзенә кагылмыйча, аның "батырлыгына" гына тукталып үзыйк.

"Газинур"ы да бит. Күпме татар егетләрен "Газинурча" үләргә өндәде.

"Күкрәк белән амбразура каплау". Советлар Союзында эшләнгән һәр эш, һәр гамәл шәрә күкрәк белән тимер-бетон амбразура каплау иде. Завод-фабрикада, кыр эшләрендә, диңгезчелектә, кыскасы, бөтен илне чорнап алган социалистик ярышта Александр Матросов "подвигын" кабатлау күпме гариплек, күпме инвалидлык бирде. Әгәр шушы тоташ томаналык минем үземне дә икенче группалы инвалидлык белән бүләкләмәгән булса, бу турыда язып та тормас идем.

Татарлар сугышта, Тукаебыз әйткәнчә, "арысландай көчлеләр", ә инде җәмгыять өлкәсендә, көндәлек тормыш, яшәеш хакыйкатен яклаганда... Әйтмик бу турыда. Туры әйткән туганына ярамаган. Русия парламентында еллар буе ыштан төбен туздырган татар депутатлары, Татарстанның Югары Советында трибунага чыгып бер кәлимә татарча сөйләргә куркудан чалбарларын чылатып утыручы "батырларыбыз" без биргән бәяне ишетү белән итәк астыннан ут йөртә башлаячаклар.

Гаҗәп авыр, кай очракта бөтенләй мөмкин түгел икән ул менталитетны үзгәртү. Ялганга, күзбуяуга инану күзәнәкләребезгә шулкадәр нык сеңгән, без әле һаман кемнеңдер җилкәбезгә атланып, камчылап куып йөртүенә өметләнеп яшибез.

Алман халкын ут эченә куар алдыннан Гитлер немецларнең тамагын туйдырды, эшсезлекне бетерде, җәмгыятьнең котын алып торган җинаятьчелекне юкка чыгарды. Димәк, канлы палач халыкка башта күпмедер игелек тә күрсәтте. Ә менә бүгенге көндә Русия тәхетенә үрмәләүче Жириновский әлегә халык өчен әнә очы чаклы эш тә майтармаган. Ә нишләп соң урыс халкы шамакайланучы шушы кеше кулына үзенең язмышын, киләчәген тапшырырга ашыга? Гасырлар буе урысларны (шул исәптән безне дә) ялган миф белән тукланырга өйрәткәннәр. Алкоголик аракысыз яши алмый, без - ялгансыз.

2

Вилнең "ялган империясенә" ялгыз каршы чыгуы турында мин соңга калыбрак ишеттем. Ишетү белән аңа чылтыраттым. Сөйләшә башлау белән телефон чыбыгына кемнеңдер "өстәлүе" сизелде. Башта челт итеп нәрсәдер зыңгылдап алды да, фон барлыкка килде, ишетелү тоныкланды.

- Яңа КГБ тыңлыймыни сине, Вил? - дип сорыйм.

- Ничек инде алар шушындый мөмкинлектән баш тартсыннар, тыңлыйлар, билгеле, - диде фән докторы.

- Урамда йөргәндә "ялгыш" машина астында калудан курыкмыйсыңмы?

- Юк, курыкмыйм, - диде Мирзаянов тыныч кына. - Чит ил галимнәренә, тынычлык көрәшчеләренә мәгълүм булды бит минем утырып чыгуым. Алар да бит күзәтеп торалар. Ежов, Берия чоры түгел бит. Хәзер сак кыланалар.

Чыннан да, чит ил газеталары, радио, телевидение Вил турында шактый күп мәгълүматлар биреп өлгергән иде инде. Ләкин АКШта, бит карт журналист, кеше психологиясен азрак чамалыйм. Вилнең "ашәкелек империясе"нә юнәлтелгән гыйсьяны юан башы белән гаилә иминлегенә китереп кундырган.

Әнә, олы малайлары Искәндәр кроссовкасын ямап утыра. Фән докторы, профессор малае. Вил Мирзаяновның профессорлыгы "почта ящигында", хезмәт хакы икеләтә, хәтта өчләтә түләнгән җирдә узды. Әле һаман башын иеп эшләп йөргән булса, акчасы май яккан ипекәйгә генә түгел, аш үтсен өчен йотып җибәрелә торган бер рюмка коньякка да, балык уылдыгына да җитеп торыр иде.

Мирзаяновлар фатирында китап күп, чисталык, музыка тыңларга, спорт белән шөгыльләнергә кирәкле әсбаплар мул, ә инде "кара көннәр" килгәч кирәк булыр дип махсус алып куелган әйберләр бөтенләй юк, диярлек.

Мәскәүгә татар артистлары килдеме, милли мәсьәләне хәл итәргә

җир шарында яшәүче халыкларның язмышын бугазлап торучы башка көчле илләрдә дәүләт һәм хөкүмәт дәрәҗәсендә Мирзаяновны яклап чыкмадылар. Аларның үзләренең дә күтләре буклы иде. Сасысы дөньяга таралыр дип курыктылар.

Ниһаять, мин Вилнең фатирында. Бу гаилә Мәскәүнең "авыл башында". "Новогиреево" станциясеннән соң егерме минут чамасы троллейбус белән барганнан соң, җәяүләп чиркәүне, урыс зиратын үткәч, кыр-яланнар башланган җирдә яши. Тугыз катлы индустриаль кетәк. Лифт кабинасы, йорт диварлары "белемле" варварлар иҗаты белән капланган.

Кая карама - җимереклек. Җитмешенче елларда салынган йорт инде күпмедер процентка харабәгә әйләнгән.

Вил кече малае Солтан белән каядыр чыгып киткән иде. Мине аның хатыны татар шагыйрәсе Нурия Измайлова каршы алды. Аның бит иҗаты гына түгел, йөзе дә көлач. Шул йөзенә гаилә өстендә куерган кара болыт шәүләсе, маңгаена, күз тепләренә хәсрәт билгеләре кунып өлгергән. Үзе һаман елмая. Сер бирмәскә тырыша. Мин

татарлар җыелдымы, иң беренче булып Вил үзе, ул эштә, командировкада булганда Нурия килә иде. Әгәр һәр татар гаиләсендә Мирзаяновларга хас саф, егәрле фикердакырлек хөкем итсә, мөстәкыйльлек юлында без инде әллә нинди зур уңышларга ирешкән булыр идек.

3

Кече малае Солтан белән Вил кайтып керде. Әткәләре эшкә йөрми башлагач кемгә бәйрәм килгән? Билгеле, бәләкәй малайга. Көнне, эштә калган вакытны азык-төлек, киемсалым чиратында үткәргәнлектән, балаларыбыз ятим үсте безнең. "Нет худа без добра", - диләр урыслар. Олы малайның дәресләрен карарга, бәләкәй малай белән чыгып йөрергә, төрле күргәзмәләргә барырга мөмкинлек бирделәр, дип шатлана Лубянканың корыч тырнагына эләккән галим.

Рәсемдә: Вил МИРЗАЯНОВ олы улы Искәндәр, кече улы Солтан һәм хатыны Нурия белән (гаилә альбомыннан).

(Дәвамы бар.)

Тормышның үзеннән дә остарак, талантлырак язучы юктыр. Бальзак шулай дигән. Чыннан да, сюжетларны бик оста кора язмыш диганең. Бер дә очрашырга тиеш булмаган адәмнәрне күрештерә. Үкенмәс кешеләрне дә үкендерә, тәүбә иттерә... Тугрылык һәм хыянәт, рәхимсезлек һәм мәрхәмәт, бәхет һәм михнәт маңгайга-маңгай бәрелдергән, гыйбрәте белән риваятькә әйләнердәй очрак-вакыйгалар да аз булмый бу тормышта.

Ихлас күңелдән

Балкондагы малай

Мин дә гомердә төрле кешеләр белән очраштым. Алардан ис китеп тыңлардай хикәятләрне дә күп ишеттем. Нәкъ менә тормыш-язучы үзе иҗат иткән "хикәя"ләр - мин белгән-күргән гап-гади кешеләр кичергән вакыйга-хәлләр иде алар. Ә менә бу тормыш хикәясен күршем Мәрьям апа Ризванова сөйләде.

... Моннан 14 ел элек шундый хәлгә тап булдым: декабрьнең салкын кичендә эштән кайтып бара идем, бер баланың өрнеп елаганын ишетеп туктап калдым. Таш йортның өченче катында балконнан килә иде бу елау тавышы. "Ни булды? Нишләп елыйсың? Ник өйгә кермисең?" Бу сорауларыма 4-5 яшьләрдәге малай сулкылдавыннан туктаган араларда өзеп-өзеп кенә җавап бирде: "Джек өйгә кереп китте дә ишек ябылды, мин берничек тә ачалмыйм. Әти өйдә юк," - ди бу. "Джек кем соң?" - дим. "Овчарка. Этебез," - ди малай. Баланың 30 градуска якын суыкта күлмәкчән басып торуын уйлап үзәкләрем өзелде. Хәлне тиз-тиз аңлатып яныннан узып баручы берничә кешедән ярдәм дә сорадым. Тик туктаучылар булмады. Ике ир-ат үтенечемне ишетмәмешкә салынып үз юлларына ашыктылар. Менә бер егет үтеп китте, менә озын буйлы бер кыз да сүзләремә колак салмады... Ниһаять, бер хатын минем дә, баланың да аянычлы хәленә төшенде. "Әйдәгез, тизрәк малайның фатирына керик," - дип подъездга таба йөгерде ул. Фатир ишеге ачык иде. Тик бозау хәтле этне күргәч, кыюлыгыбыз шиңде. Исеме белән ялынып-ялварып дәшүебезгә карамастан, эт гөбедән чыккандай калын, шыксыз тавышы белән өрүдән туктамады. Шау-шуга күрше ишектән бер хатын чыкты. Аңа да хәлне сөйләп күрсәттек.

- И мескен бала, күрмәгәне калмады шул сабыйның. Ярты ел элек кенә шырпы белән уйнап бит алмаларын пешергән иде. Әнисе үлде аның. Әтисе эчә. Бала менә шулай ташландык инде хәзер... - дип сөйләнә-сөйләнә күрше хатын миңа зур гына такта китереп тоттырды. Малай фатирына шул тактага ышыкланып (эт һөҗүменнән сакланып) барып кердек. Джек баштарак безнең тарафка ярсып-ярсып ыргылса да, соңыннан, балкондагы нәни дустына ярдәм итәргә теләвебезне аңлап булса кирәк, туктады. Балкон ишеген без дә көчкә ачтык, бозга туңып каткан иде ул. Өшеп, бөкрәеп төшкән малайны күтәреп алып кердек тә җыелмаган урын өстенә салдык. Кул-аякларын ышкып җылытырга ашыктык. Мин кухняда чәй кайнарлаттым. Фатир буйлап йөргәндә таң калдым - һәрнәрсә ватылган-җимерелгән, әйберләр язган-тузган, кайгыртучан хуҗа белән уңган хуҗабикә юклыгы сизелеп тора. Чәй эчерткәндә малайның йөзендәге пешүдән калган җәрәхәт-эзләренә игътибар итүем, аны бик кызгануым исемдә... Нәни хуҗасын - малайны кызгангандай гел аның тирәсендә йөргән чем-кара, олы эт тә исемдә калган. Бер шыңшыгандай, бер юаткандай үзәк өзгеч авазлар чыгара-чыгара малайның әле кулларын, әле битләрен ялады, өстендәге юрганын рәтләгәндәй итте... Бирсен иде ходай кайбер адәмнәрнең күңеленә дә менә шул эттәге шәфкатьлелекне, башка берәүнең хәленә керүне, дип уйлаганымны хәтерлим.

Быел кыш апа белән Казанга бардык. Ленин урамындагы җиләк-җимеш сулары сата торган кибеткә кердек. Балаларга "Пепси", "Фанта" алырга иде исәп. Кибетнең бер почмагында сыра саталар. Бервакыт шул почмакка ишектән шау-гөр килеп кереп тулган егетләр җыелды. Төрткәләшәләр, теш арасыннан гына текеренәләр, ачы итеп сүгенәләр... Карамас җиреңнән карарсың шулар ягына. "Натуральный" күн куртка, елкылдап торган чәшке бүрек кигән егетләрнең берсе миңа нишләптер таныш тоелды. Игътибар беләнрәк карый башладым: битләрендәге җәрәхәт урыннарын күргәч, шунда ук исемә төште: балкондагы малай бит бу!

Шул егет янына барасым, хәлләрен сорашасым килде. Ничек тәвәккәлләгәнмендер, апамның: "Кая барасың? Башкисәрләр янынамы?" - дип усал пышылдавы да туктата алмады.

"Энем, син Илшат исемлеме?" - дип соравыма, егет миңа таба кырт кына борылды да "бу тагын нинди бөҗәк?" дигән кебек, өстән аска әре генә карап: "Шулай, түтәй. А чего тебе надо?" - диде. "Джек исемле этең дә бар идеме?" дип әрсезләнеп дәвам иттем. Егетнең боз кебек салкын күзләренә уй-гамь әсәре кергәндәй булды, карашына бер җылылык инде. "Бар иде шул. Ә сез каян беләсез соң?" "Кыш көне балконда торганыңны да хәтерлисеңдер?" "Юк, түтәй, минем белән андый хәл булмады. Башка кеше белән бутыйсыздыр. Алай дисәң инде, исемне дә дөрес әйттегез, Джекны да беләсез..." "Сиңа балконда булган хәлләр турында әтиең дә, күршеләрең дә сөйләмәдемени?" - дип "бәйләнүемне" дәвам иттем. "Апа, менә тагын ялгыштыгыз, минем әтием дә, күршеләрем дә булмады. Мин бит балалар йортында, Чистай детдомында үстем".

Шуның белән безнең сүз өзелде. Бүгенге хәлләре, ничек яшәве турында да бик сорыйсым килгән иде, югыйсә. Тышкы кыяфәте, затлы киемнәре... кибеттәгеләрнең купшы егетләр артыннан: "Хулиганнар, шулар инде кеше талап көн күрә", дип сөйләнеп калулары әллә никадәр борчулы уй, мең төрле сорау тудырды. Балкондагы 4-5 яшьлек малайның сулыгып-сулыгып елаганын кабат ишеткәндәй булдым...

Үзе турында уйлаганымны сизенеме, Илшат, төркеменнән аерыла төшеп, миңа борылып карады. Күзләрендәге салкын гамьсезлек бөтенләй юкка чыккан, карашы бик моңсу иде егетнең...

Насимә САДЫЙКОВА.

13 нче БАГАНА

Элегрәк академик исемен гомер буе фән белән шөгыльләнгән кешеләргә генә бирәләр иде. Хәзер исә, әгәр син хакимият башында булсаң, шул җитә. Менә кызык заман! Укыр өчен дә хәзер баш кирәк түгел, кесәң калын булса, әллә нинди дипломнар алырга була. Тора-бара интеллектуалларны "Кызыл китап" буенча гына эзләргә калса да гаҗәпләнмим. Мамонт кебек үлеп бетәрләр алар болай булса.

И.ХӘБРИ.
Казан.

* * *

Һич икеләнмичә әйтә алам: элеккеге җитәкчеләребезнең Американы куып җитеп узып китәрбез дигән хыялы тәки чынга ашты. Бөтен нәрсәбез Америкадагыча. Бик үк ак төстә булмаса да Ак йорт та бар бездә, президентлар да ишәйгәннән- ишәя, долларны да күрдек. Тик бер нәрсәдә аерма кала әлегә. Ул да булса...

Америкада президентлар 4 ел саен алмашынып тора. Ә бездә властька бер утырсалар, хәлләреннән берни килмәсә дә, җан тәслим кылганчы утыралар.

Татарстан Югары Советы сессиясен генә алыйк. Ничә карама, 7-8 кеше алып бара бит ул сессияне. Калган депутатлар я йокымсырап утыра, я иртәгә ни буласын эчтән фаразлый. Дөресен әйткәндә, кәҗә киртәсе корырлык та тәкъдим кертә алмаганнарны нигә тотарга? Кулларын кысып озатырга вакыт аларны.

Фәрит ЮНЫСОВ.
Апас.

* * *

Хөрмәтле "13 нче багана!"

Сиңа бер авыл кызы яза. Мин җырчы Айдар Галимовның үзенә, тавышына, үзүзен тотышына гашыйк.

Сезнең газетта мин Айдар Галимов турында бик зур итеп язылган мәкалә укырга телим. Ул язмада үземне кызыксындырган һәмма сорауларга җавап табармын дип өметләнәм.

Җырчыга табынучы бер кыз.
(Адресымны язмыйм)

Редакциядән: адресыгызны язмаган тутаи! Яраткан җырчыгыз Айдар Галимов турында бик зур итеп без әле бер ай элек кенә, узган елның 23 декабрь санында ("Т.Я." N 75-76, 1993) язып чыктык. Анда җырчының тормыш юлы да, ничегрәк сәхнәгә килүе дә тасвирланган, бик матур, елмаеп төшкән фотосурәте дә бар. Иренмичә, шул санны табып укырсыз дип өметләнеп калабыз.

* * *

Бу Казан дикторларына исем китә минем. Ике җөмләне дә кәгазьгә карамыйча әйтә алмыйлар. Карагыз, өйрәнегез әзрәк Мәскәү дикторларыннан. Аларның әйтеп бетерергә ярамаган сүзләре күз карашларыннан аңлашыла. Бөтенесен үк язып тормыйм да инде. Дөресен әйткәндә, ни татарча, ни урысча рәтләп сөйли белмиләр, әле гел ялгышалар.

Туры әйткәнем өчен ачуланмагыз.

Галия ИСЛАМОВА.
Казан.

* * *

"13 нче багана!" Мин синең аша эндәшәм, зинһар, хатымны бастыр. Исәнмесез, 1986 елда Алуштада очрашкан дус! Исегездәме, 8 Март бәйрәмен күңелле итеп үткәрдек? Сезнең белән шахмат уйнаган Зөфәр һәм аның хатыны янәшәсендә утыручы кеше язды бу хатны. Бүгенге көндә сез бәхетлеме? Хат язарга теләсәгез, адресым редакциядә булыр.

* * *

Хөрмәтле редакция! Мин сезнең газетаны гомер буе алдырам. Аңардан наз алып, көч алып яшим. Мин элек Әлмәт шәһәрендә яшәдем. Хәзер авылга кайтып ике йорт салдым. Бакчам бар, терлекләр асрап ятам. Минем хатка шәһәрдә яшәсә дә, авылга кайтырга теләге булган, эштән курыкмаган 45-55 яшьләрдәге берәр хатын-кыз җавап бирсә, барыгызга да рәхмәтле булыр идем.

Г.Р.
(Адресым редакциядә).

"Сәламәтлек кенә булсын, калганын сатып алырбыз" афоризмы – бәйрәмнәрдәге яхшы теләк. Әмма еш кына без үзебез үк үз сәламәтлегебезгә игътибар итмичә шундый халәткә җитәбез ки, даруханәләрне урап узып булмый башлый. Даруханәләр Казанда байтак, алар 85 кә җитә. Ә менә кирәкле даруларны гына, кайбер көнне сиксән бишеннән эзләсәң дә, таба алмыйсың. Дарулар кытлыгы. Халыкны аларның бәясе дә борчый. Бу мәсьәләгә республиканың сәламәтлек саклау министры Рамил Госман улы Хәбриев кайбер ачыклыклар кертте.



Министрлык бүген үк җитәрлек дәрәҗәдә дару кайтарта ала, әмма аларны арзанайту безнең кулдан килми. Төрле льготалардан файдаланучы авырулар болай да бюджетка авыр йөк. Бу - бер. Икенчедән, "Ашыгыч ярдәм" хезмәтендә эшләүче табиблар күп кенә өйләрдә коточкыч күп дарулар саклануын искәртәләр. Өченчедән, дарулар хәзер малтабарлар аша да сатуга китә. Без соңгысына каршы да түгел. Әмма "Татарстанфармация" дәүләт предприятиесе шикелле хосусый фирмаларның сату-алуга лага тутырылган дарулар ясый башлауны күздә тота. Моңа кадәр республикада мондый дарулар җитештерелмәде. Чит ил партнерлары белән уртак ширкәтләр төзергә дә планлаштырабыз. Әйтик, алар әзер чимал саталар, ә дару ясау - бездән. Беренчедән, ул арзанга төшсә, икенчедән, җитештерү базасы кыскартылмаячак.

Быел Кама Аланын-

Көнүзәк әңгәмә

Дарусыз шифа юк...

лицензияләре генә булсын. Сәламәт конкуренция даруларның бәясен генә арзанайтыр иде. Югыйсә, соңгы вакытта даруларның бәясе үзебездә ясалганыныкы да, чит дәүләттән кайтартылганныкы да ай саен берьярым мәртәбә артып килә. Аннан соң, әлегәчә дарулар безгә үзәкләштерелгән система аша федераль бюджеттан бүлеп бирелә иде. Аның аша дарулар узләренең төп бәяләреннән 20,50,70 әр процент льготалы итеп җибәрелеп килделәр, ә 1994 елны РФ Финанс министрлыгы бу льготаларны бөтенләй бетерде. Дөрес, узган ел Русия чит илдән 40 миллион долларга дару сатып алган иде. Ул безнең республикага да аз гына өлеш чыгарды.

- Республикабызның үз җитештерү базасы да бар. Аның мөмкинлекләрен киңәйтү юнәлешендә ниләр эшләнә?

- "Татхимфармпрепараты" берләшмәсе 60 төргә якын медикаментлар җитештерә. Берләшмә хәзерге вакытта ампулага... да кытайлар белән берлектә планлаштырылган дару ясау заводы төзү тәгәлләнәчәк. Анда Кытай технологиясе буенча женьшень препаратлары җитештереләчәк, елъярымнан соң женьшеньне үзебездә үсүче левзея үләне алыштырачак.

Киләчәктә "Татарстанфармация" берләшмәсе инглиз-һинд фирмасы белән берлектә инфузия эремәсе җитештерә башлаячак.

Тагы да шуны искәртер идем, табиблар соңгы вакытта рецептка әзер дарулар гына язып бирү белән мәшгуль. Югыйсә, кушып әзерләнүче препаратлар да бар бит бездә.

- Хәзер бик күп дарулар кайтартыла. Кайберләрен табиблар үзләре дә белеп бетермиләр...

- Бик дөрес. Шуңа күрә без дарулар турындагы мәгълүматларны туплаучы республика үзәге оештырырга булдык. Бу үзәк дәвалау учреждениеләре, табиблар белән эшли башлаячак. Кулланудан алынган, яисә киләчәктә куллануга кертеләчәк дарулар турында хәбәр итеп торырга ниятлибез.

- Рамил Госманович, даруларга льготалар хакында сорау бирми калып булмый. Киләчәктә ул ни дәрәҗәдә сакланачак?

- Беренчедән, республика аптекаларыннан сатыла торган бөтен медикаментларның 60 проценты льготалы шартларда җибәрелә. Бүген льготадан бер миллионга якын кеше файдалана. Бу исәпкә Бөек Ватан сугышы инвалидлары, 3 яшькә кадәрге һәм күп балалы гаиләдәге 16 яшькәчә булган балалар, кайбер категория пенсионерлар керә. Әмма күп препаратлар еш кына очраклы кешеләр кулына элэгә. Шуңа күрә льготалы авыруларны рәнҗетмәү һәм рецептлар язуны тәртипкә салу өчен даруханәләрдә махсус дару чеклары кертергә уйлыйбыз.

Рәүф ХӨСНЕТДИНОВ.

Рәсемдә: сәламәтлек саклау министры Р.ХӘБРИЕВ.

Рамил ГАЛИЕВ фотосы.

Кемгә машина, кемгә...

Инфляция көннән-көн котыра барган чорда халыкның яшәү дәрәҗәсен ничек билгеләргә? Акча беләнме? Юк. Хәзер тормыш дәрәҗәсен билгеләүдә тормыш-көнкүрештә кирәк булган әйберләрнең исемлеге төп рольне уйный. Бер төркем социологлар Русия гаиләләрендә сораштыру үткәргәннән соң менә нинди нәтиҗәгә килгәннәр.

Беренче урында телевизор һәм фотоаппарат. Бу әйберләр белән 31 % гаилә тәэмин ителгән. Икенче урында электр дреле - 27 %. Гаиләләрнең дүрттән бере миксер алырга өлгергән. Микродулкынлы мичкә 3 % - суыткыч-камераларына 10 % гаилә ия булган. Ә менә видеомагнитофоннылар суыткыч хуҗаларыннан 2 % азрак. Видеокамералар бөтенләй юк диярлек. Нибары 0,4 % гаиләдә генә. 7 % гаилә үзләренә болай да кысан булган фатир мәйданына пианино алып куйган. Компьютерларга карагандa, бу ике тапкырга күбрәк.

Фатирдан читкә чыгып саный башласак. Дүрттән бер гаиләнең үз бакчасы бар. Автомобильләре булганнар 19 % ка җитә. Билгеле, бу Филадельфия үк булмаса да, Рио де - Жанейро белән чагыштырырлык.

Ә хәзер иң аянычы. Соралган гаиләләрнең 21 процентында саналып киткән әйберләрнең берсе дә юк.

РАВИЛ САБЫР, ЛӘИС ЗӨЛКАРНӘЙ

АРЫСЛАННАР АРАНЫ

ГАСЫР РОМАНЫ

(Ахыры. Башы газетаның 7, 8, 9, 10, 11 саннарында.)

6

Зөлхәбирәне күтәреп килеп кергән Дулланы Чана һәм Ләбиб Ләбибечне карый торган хатын каршы алдылар.

- Күчтәнәчне кабул итеп алыгыз! Т-теге мент кебек. Уятып кына булмый малай!

- Кем соң бу? - дип сорады гаҗәпләнүеннән күзләрен акайткан Чана.

- Күп белсәң, тиз картаерсың. Мә, күтәр әле үзең. Караңгы бүлмәгә илтеп биклап куй.

Чана Зөлхәбирәне кулына алгач "ыһк" итеп куйды. Шулай да, алпантилпән килеп кенә булса да, хатынны әйткән урынга илтеп салды. Ул ишекне йозакка бикләп кире килгач, Дулла:

- Шеф кая? - дип сорады.

- Ләбиб Ләбибеч хәзергә юк әле. Сәгать икеләргә кайтып җитәчәк. Алар Ябалак белән каядыр китеп бардылар, - дип җавап кайтарды Чана.

- Ярар алайса: Мин шул вакытларга килеп җитәрмен, - дип, Дулла чыгып сыптырды.

... Зөлхәбирә уянганда радио: "Мәскәү вакыты ундүрт сәгать утыз минут", - диде. Хатын, әлбәттә, берни дә аңламады. Һәм нәрсә дә булса ачыклау өчен тонык кына ишетелгән тавышларны колакларын торгызып тыңлый башлады. Шунда аермачык булып телефон чылтыраганы тавыш ишетелде.

- Әйе, - диде берәү. Зөлхәбирә бу тавышны шундук танып алды. Тавыш база начальнигы Ләбиб Ләбибечнеке иде.

Аның телефоны Канадада эшләнгәндер, күрәсең. Чөнки бу илдә ясалган аппаратларның трубканы күтәрмичә сөйләшү өчен махсус төймәсе бар. Әңгәмәдәшнең тавышы телефонның үзендә урнашкан радио кебек нәрсә аркылы ишетелә. Зөхәбирә бу уйларны бер мизгел эчендә башыннан үткәрде дә сөйләшүне тыңларга керешә.

- Әйе. Мин тыңлыйм, - бу Ләбиб Ләбибеч.

- Ләбиб, Воробьев бу. Шундый кешене беләсеңме?

- Юк.

- Ә Лимонны?

- Аны да белмим.

- Белмәсәң, белдертербез. Ә синең Ябалагың - самурай. Считай, что он не жилец. Синең ул дурагың Идиотны бетерәм дип минем кешене, Лимонны тончыктырган. Шулай булгач, син миңа бурычлы. Дөрес сөйлимме?

- Сөйлә әйдә, сөйлә.

- Кыскасы шул. Безгә очрашырга кирәк. Сүзем телефоннан гына сөйли торган түгел. Бүген, кичке тугызда. "Ушачи"да.

- Нинди "Ушачи"?

- Шәһәр читендәге бакчаларны әйтәм, пидар. Нәрсә, әллә куркуыңнан ычкына башладыңмы? - "Ушачины" белмәскә!

* * *

- Зиннур Хөснярны табып бирегез миңа! - диде "Идел"нең баш мөхәррире Фәнз Зөлкәрнәй. - Вакыты чыкты егетнең!

Чыннан да, романның ахырын җирәбә буенча Зиннур Хөсняр язарга тиеш иде. Язган дип ишеттек. "Баш әйләнгеч булды, малай," - дип мактанып та йөргән икән.

Зиннурны Ләбиб Леронбелән эзли чыктык. Баксаң, редакциясенә (Зиннур - "Салават күпере"нең баш мөхәррире) машина алган икән. Машинаның да әле нинди. Шкап (Зиннурның кушаматы) кадәр шкап сыярлык пикап! Менә хәзер шул машинада көне-төне йөри икән ул. Эшендә, өендә, дачасында, авылында да койрыгын тота алмагач, Казан урамнарына чыгып киттек. Кырык тапкыр безнең янәп узып китте - кул күтәрсәк тә, юлына аркылы төшсәк тә, хәтта юлга ятып карасак та - барыбер туктамады...

- Машина астында калып үләр хәл юк, - диде Ләбиб. - Зиннур урынына Ркаилне генә табып бирик мәллә? Беренчедән, ул Зиннурга бик тә охшаган, икенчедән, машинасы юк.

Ркаилне "Сарман" кафесында эзләп таптык. "Урыс кышын озату" исемле шигырьләр китабы чыккан икән. Гонорар итеп алган 100 меңен урыс кышын озаткан кебек бәйрәмсәйрәмләп озаттык. Шигырь язып кына, хәтта гасыр романы иҗат итеп кенә дә җан асрап булмасын аңлаган ахыры Ркаил, икенче көнне үк, урыс кышы җиткәнче, шабашкага чыгып киткән. Татарстанның ерак бер төбәгендә дуңгыз фермасы салып ята ди әнә...

Романның ахырын бәлки язышыр дип Равил Сабырга - "Татарстан яшьләре" газетасына киттек. "Ул мондасын монда, тик монда юк", - диде Исмәгыйль Шәрәфи.

- Әнә бит ботинкасы, - диде Ләбиб, өстәл астына ымлап.

- Ну и что? - диде Исмәгыйль. - Ботинкасы монда, наские ундүртенче катта.

Баскыч буйлап йөгереп матбугат йортының түбәсенә менеп киттек.

- Әнә чалбар балагы да күренә ич, - диде Ләбиб, күккә төртеп.

Балактан тартырга дип сикереп тә карадык - буй җитмәде. Тамаклар ярылганчы: "Сабыр! "Сабыр!" - дип кычкырып та карадык - ишетмәде.

- 19 яшендә "Гасыр романы" яздырып харап иткәнбез малайны, - диде Ләбиб. - Башы күккә тигән...

Шулай итеп, мәшһүр гасыр романын төгәлләргә бер төркем язучыдан икесе генә калды.

- Син башладың, син төгәллә, - дидем Ләбибкә.

- Син уртасын яздың, урта ахырга якынрак, әйдә үлең маташ инде шунда.

Шулчак без сөйләшеп утырган бүлмәгә күтәрмә якалы кара плащ кигән берәү килеп керде.

- Мин - Баязиттан, - диде ул карлыккан тавыш белән.

Аркадан салкын урмәкүчләр йөгерде: романдагы уйдырма геройлар дөньяга күчмәгәндер бит инде...

- Баязит җиңел чыгарга тиеш, - диде күтәрмә яка. - Башка төрле язсагыз - сезгә хана.

- Изүт ирега... - дип сүз башлады Ләбиб.

- Ирек бездә, - дип бүлдерде төксе егет. - Әйбәт язсагыз - монда ыштан туздырып утырмассыз... Шылдыммы?!

(Ниһаять, бетте.)

ЮМОР һәм САТИРА

Әт ельнда - эт турында

Ришат, СПТУда укыганда, эт баласы алып кайта да "Шиза" дип исем куша. Аның: "Шиза! Шиза! Ко мне!" - дип, эт баласын чакырганын ишеткәч, Габдулла абый Ришатларның күршесе Нурдидәападан сорый:

- Нурдидә! Ул Фалих малае этенә нинди исем кушкан ул?

- Белмим бит, әй! - дип җавап бирә Нурдидә апа. - Әллә "Җиде", әллә "Сигез" шунда! "Җиде" бугай.

* * *

Ришатның эте үсеп җиткәч, беркөнне бергә укыган иптәше Фәнүс белән "Шиза"ны уйнаталар. Ришатның "Шиза"ны ата эт дип йөргәнен белгән Фәнүс:

- Яшьти! Корсагы бик олы моның, анадыр бу! - дигәч.

Ришат:

- Күп ашый ул! - дип җавап бирә.

Уйната торгач, эт корсагына әйләнеп, имиләре күренә.

- Ана эт бу! Әнә бит имиләре дә бар! - ди Фәнүс.

- Менә бу сиңа фәлән нәрсәмени! - дип Ришат күлмәк сәдәфен ычкындырып күкрәгенә төртеп күрсәтә. - Мин дә хатын-кызмыни?!

Ун көннән соң ата эт "Шиза"ның биш маэмае туа.

Ринат ТАҖЕТДИНОВ.
Сарман районы,
Морбаш авылы.

Шулай бервакыт

Умырзая яфрак ярмас

Җитмешенче елларда Октябрь бәйрәме көнендә механизаторлар Барый абый белән Габдулла абый ару гына төчкертәләр дә, ул вакытта бик популяр булган "Умырзая" җырын җырлыйлар. Җыр икесенә дә ошап киткәч, башыннан башлап тагын ун тапкыр җырлыйлар.Аларның кордашы, гомерлек дуслары, "Сельхозтехника"да токарь булып эшләүче Мөхәмәтдин абый бу турыда ишетә дә, Габдулла абый ремонтка төшкәч: "Ну, Габдулла, малай, теге көнне "Умырзая"ны каты сиптергәнсез! Быел умырзаялар чәчәк ату түгел, яфрак та ярмас инде!" - дип куя.

"Кирәк саен килеп алырмын!"

Сугыштан соңгы еллар. Фәрхиямал түтине ит налогын түләргә дип көн саен идарәгә чакыралар. Фәрхиямал түти төрле сәбәпләр табып килмәгәч: "Ник алып килмәдең?" - дип, исполнитель Банат апаны сүгәләр. Икенче көнне тагын җибәргәч, Банат апа Фәрхиямал түтиләргә керә дә:

- Түти! Идарәдә ит еләшәләр, хәзер үк килеп җитсен диделәр! - ди.

- Банат, кызым! Ник аны үзең генә алып килмәдең соң? - ди идарәгә барасы килмәгән Фәрхиямал түти.

- Үзе килеп, ведомостька кул куеп алсын! - диделәр.

Фәрхиямал түти идарәгә кергәндә, аны күптән көтеп утырган вәкил ит налогы кәгазьләренә карап:

- Түти! Синең итең бик күп җыелган икән монда! - ди.

Беркатлы Фәрхиямал түти:

- Җыелсын, үскәнем! Кирәк саен керәп алырмын! - дип җавап бирә.

Хәдичә кодачаны!

Куҗактан Галим белән Сәлим акчалары булган саен кибеттән бер ярты алып чыгалар. Аннан күршедәге Салихҗан абыйларга керәп, стакан, ипи һәм суган алып, теге яртыны бушаталар да, икесе генә белгән, бер генә куплетлы шушы җырны унар мәртәбә җырлый торган булалар:

Эчәбез дә бетерәбез -
Җитмеш биш сум акчаны.
Барабыз да кочаклыйбыз
Хәдичә кодачаны!

КӨЛДЕРГЕЧЛӘР

Илья Муромец иртән уянып китсә - бөтен тирә-юньнең асты-өскә килгән, агачлар тамырлары белән йолкынган, Убырлы карчыкны кемдер башы белән аска каратып килесенә тыгып куйган. Батыр аны тартып чыгара:

- Кем рәнҗетте сине, әбекәй?

- Ой! - дип елап җибәрә Убырлы карчык. - Айнык чагында фәрештә кебек кеше инде үзең, Илюша!

* * *

Мужик троллейбуска утырырга маташа:

- Иптәшләр, минем йомыркам бар.

- Монда бөтен кеше йомыркалы! - дип җавап бирә халык.

- Ләкин миндә тавык йомыркасы.

- Ә-ә... Үткәреп җибәрегез инвалидны.

* * *

Гали, - ди укытучы дәрес вакытында, - төрт әле күршеңә, уянсын.

- Ә ни өчен мин? Аның йокыга талуына сез сәбәпче лабаса!

* * *

- Менә хәзер без сезне көмешкә кайнатканын өчен хөкемгә тартабыз инде! - ди участок инспекторы тентүдән соң.

- Ләкин бит мин көмешкә кумадым.

- Анысы әһәмиятле түгел, аппаратыгыз бар бит!

- Алайса, мине көчләгән өчен дә хөкем итегез.

- Сез кемне дә булса көчләдегезме?

- Юк, әмма аппаратым бит бар!

* * *

- Аларның ярәшүенә инде ун елдан артык дисез. Ә нигә һаман өйләнешмиләр?

- Кәләше егетә эчеп йөргән чакта аңа кияүгә чыгарга теләми, ә тегесенең айныгач өйләнәсе килми.

* * *

Музыка укытучысы Вәлигә:

- Әгәр дәрестә тәртип бозсаң, әтиең белән әниеңә балагыз талантлы дип әйтәм.

* * *

Коньяк бәясенең күтәрелүе кемгә ничек тәэсир иткән?

Эшче: "Безгә берничек тә тәэсир итмәде. Спиртны элек ничек урлаган булсак, хәзер дә шулай урлыйбыз".

Крәстиән: "Безгә дә. Көмешкәне ничек куган булсак, шулай куябыз".

Аппаратчы: "Безне элек тә бушлай сыйлыйлар иде, хәзер дә шулай".

Аларда шулай!

Ашау - байдан, үлем - ходайдан

Яшәү мәгънәсен сукбайлыкта күргән америкалы Гай Трэкны кайда йокларга, нәрсә ашарга, ничек яшәргә дигән сораулар борчымый: нәрсә булса, шул булсын - тик ходай аны сукбайлыктан гына аермасын!

Зимагорлыкта йөри торгач бетешеп китсә, ул сырхауханәгә бара, качып кереп, буш караватка менеп ята һәм, фаш ителеп, артына тибеп чыгарганчы казна хисабына ашап-эчеп ял итә.

- Күп кешеләр сырхауханәдән куркалар, ә минем өчен ул чын җәннәт, - ди сукбай. - Мин җылы, йомшак урында рәхәтләнеп ял итәм. Биредә җәймәләрне көн саен алыштырып торалар, ашау турында уйлыйсы юк, кайда кунармын икән дип баш ватасы юк, ботинкамны караклар яки хулиганнар салдырып алмагае дип калтырап торасы юк.

Дүрт сәгать саен чибәр һәм кайгыртучан шәфкать туташы кайнар ризык һәм тәмле эчемлекләр китерә. Минем ише егеткә тагын нәрсә кирәк! Кыскасы, оҗмах инде, оҗмах!

Гай Трэкка 36 яшь. Соңгы алты елда ул инде унлаган сырхауханәдә "дәваланып" чыгарга өлгергән. Бу эштә ул тәмам шомарып беткән, хәсталы кеше ролен уйнау аңа берни түгел.

- Дусларым миннән көнләшә, - дип мактана Гай, - чөнки берничә көн "дәваланганнан" соң мин алар янына яңадан туган кебек сафланып һәм тазарып кайтам.

Сырхауханәгә Гай беренче тапкыр чын пациент буларак, законлы нигездә эләккән, аны машина таптаган булган.

- Мине өч көнгә сырхауханәгә салдылар, бу өч көн минем өчен җәннәткә эләгү белән бер булды, - дип искә ала зимагор. - Ничә ел эчендә беренче тапкыр мин чиста, тук идем, туйганчы йокладым.

Менә шул вакыйгадан соң Гай Трэк дежур сырхауханәләргә үтеп керү буенча специальләшкән.

- Иң мөһиме - качып кергәндә эләкмәскә кирәк, - ди Гай. - Ә инде юрган астына кереп яткач, сиңа бөтенесен китерәләр һәм медперсонал аны-моны аңлаганчы берничә көн үтә, син рәхәтләнеп ял итәсең. Трэкны берничә тапкыр сырхауханәдән туп-туры төрмәгә озатканнар. Ләкин ул моңа үпкәләми, чөнки төрмәдә дә яхшы ашаталар, чиста урын-җирдә яткыралар.

("Мегаполис-континент").

ШКББ

Хөрмәтле конкурсантларыбыз, ягъни мәсәлән, ШКББга адреслап шаян, көлке, усал шигырьләр җибәрүчеләр! Конкурсыбызга 1993 ел ахырында нокта куелмаганын абайлагансыздыр, шәт. Сәбәбе бик гади: соңгы айларда шигырьләрегез ишелеп килә башлады. Иҗатыгыз дәрьясын бумас өчен, без конкурсны марткача дәвам итәргә булдык. Рәхәтләнеп языгыз, дуслар, тик вакытның аз калганын да онытып бетермәгез.

Мәскәүдәге абзый уйлары

Көзләрдән соң язлар килми...

Равил ФӘЙЗУЛЛИН

Көзләрдән соң язлар килми икән,
Мин килер дип уйлаган идем,
Уракны да яңа ел җиткәнче
Җыярбыз дип уйлаган идем.
Бер ай алдан килде бу кыш-явыз,
Кар өстеннән урдык икмәкне,
Нинди генә гөнаһыбыз өчен
Бирде икән хода кирәкне?
Күрשеләр дә икътер үги итә,
Азык җибәрмиләр ашарга!
СССРны таркатмыйча гына
Кирәк булган икән яшәргә.
Указ чыкмас борын килде бу кыш,
Бураннары тышта котыра.
"Көзләрдән соң язлар килми икән,-
Татарин был прав" - дип утырам.

Рөстәм ЗӘКИЕВ.
Чаллы.

Дию дә качар!

Явыз хатын котырынып китсә әгәр,
Телен касш камчы итеп болгый икән,
Авызыннан ут-ялкыннар бөрки икән!
Һич нәрсәнең матурлыгын тоймый икән!
Иле күзен кан басканын сизми икән.
Пахак сүзне каян гына таба икән?
Гаепсезне гаепледәй итә икән,
Өче теле елан булып чага икән.
Зәһәрләнеп тузынганда явыз хатын
Тирә-юньгә җил-бураннар чәчә икән,
Ул бураннар дивоне дә бөгә икән -
Пәри заты юашланып кача икән.
Шул явызга түзеп торган ирга дию:
"Качыйк моннан, адәми зат!" - димәс микән?
Каф тавының аръягына китсәләр дә,
Явыз хатын арттан куа килмәс микән?

Ольга ГЫЙМАДИЕВА.
Кукмара районы, Кәркәвеч авылы.

Ходай кушса

Авылыбыз үз җаена яшәп бара,
Район үзәккә ерак түгел, якын ара
Түрәләр дә килеп тора минут саен,
Ферма-склад тирәсенә, табып җаен.
- Ходай кушса, сабантуйга газлы итәм,
Һәр йозага газ кермәсә, көфер китәм!
Хуҗа сүзе бер була ул, шәт, белерсез,
Зәңгәр утны җәй булмаса, көз күрерсез!
Шулай диеп күкрәк сукты хуҗа кеше.
Көз дә үтте, кыш та җитте - бетми эше,
Көн итабез торбаларга карый-карый
Хатын-кызлар кер эләләр, эшкә ярый.
Җәен таган атыналар бала-чага,
Торбаларны кар каплагач, шуа чана...
Без өметтә, өметсез тик шайтан диләр,
Ходай кушса, газлы булыр безнең өйләр.
Кыш булмаса, алда бар бит тагын язы -
Безгә җиткәч, бетә күрмәсен тик газы!

Зөфәр РАМАЗАНОВ,
"Арча" совхозы.

ТЯ

Баш мөхәррир
Исмәгыйль ШӘРӘФИЕВ

ЯЗЫГЫЗ:
420066, Казан, Декабристлар урамы,2.
"Татарстан яшьләре"

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
53-07-52 - баш мөхәррир урынбасары
53-07-54 - җаваплы сәркатип, реклама
53-07-58 - хатлар бүлеге
53-07-54 - тәрҗемә
53-07-52 - табигать, авыл тормышы
53-07-56 - сәясәт, мәдәният-сәнгать
53-07-50 - рәссам, компьютер операторлары

"Татарстан яшьләре"н гамәлгә куючылар - Татарстан Республикасының Яшьләр оешмалары советы, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, редакциянең хезмәт коллективы.

Газета Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 268-нче номерлы таныклык белән теркәлде.

"Т.Я" сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

Реклама һәм белдерүләрдәге мәгълүматларның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

Редакциянең исәп-хисап счеты:
Р/с 700161998/700751
ВКАБ РКЦ ГЦБ г.Казани,
МФО 265005
Индекс - 54121
Тираж - 200000

Татарстан газета-журналлар басмаханәсе.

Газета басылуга кул кую график буенча 18 сәгатьтә. Бу санга 15 сәгатьтә кул куелды.

Заказ 6200